ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.09.2025 г. Заинск № 426

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 17 декабрендәге 644 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль якланганлык дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән чаралар күрү максатларында һәм Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 17 декабрендәге 644 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» карары белән расланган 2 нче кушымтаның «Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен исәпләү, билгеләү һәм үзгәртү тәртибе» II өлешенә (23.05.2022 ел, №249, 08.07.2022 ел, № 337, 03.10.2022 ел, № 506, 07.12.2022 ел, № 620, 07.04.2023 ел, № 245, 16.07.2024 ел, № 408, 21.02.2025 ел, 83 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Бишенче абзацка түбәндәге редакциядә җөмлә өстәргә: «Зәй районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге – «Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча ведомстводан тыш сак идарәсе» Федераль дәүләт казна учреждениеcе филиалы хезмәткәрләренең балалары өчен», ата-ана түләве, ата-анадан (законлы вәкилдән) бирелгән гариза нигезендә, туу турында таныклык, ата-ананың эш урынынна белешмә (законлы Зәй районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәре булган вәкил) – «Россия Федерациясе Милли гвардия

гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе» Федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы».
2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru  һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 01 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
9-90-15